КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1028

«Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлаштыру өлешендә Татарстан Республикасында «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәле камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 8 май, ФЗ-83 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә, дәүләт идарәсе системасын цифрлы трансформацияләүне тормышка ашыруны һәм, тотрыклы мәгълүмат иминлеге һәм Татарстан Республикасының клиент-юнәлешле технологик инфраструктурасын формалаштыру белән процессларны үтәли тармакара цифрлаштыруны тәэмин итә торган платформа чишелешләрен һәм цифрлы технологияләрне кертеп, дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә функцияләре нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына беркетелгән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне аның эшчәнлегенең төп максаты итеп билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – казна учреждениесе) гамәлгә куючы функцияләрен һәм

вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

60 көн эчендә казна учреждениесе уставын расларга һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән күздә тотылган кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

казна учреждениесе уставын раслаганнан соң 10 көн эчендә казна учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетү өчен Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрергә;

«Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе (алга таба – унитар предприятие) белән берлектә, унитар предприятиенең 132 штат берәмлеген казна учреждениесенә закон белән билгеләнгән тәртиптә күчерүне тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 132 берәмлек тәшкил итә;

казна учреждениесе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына казна учреждениесе уставын раслаган көннән 30 көн эчендә аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә итү хокукында казна учреждениесенә беркетергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин